КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 9 август

г.Казань

№ 781

«Татарстан Республикасы Дәүләт юридик бюросы» дәүләт казна учреждениесе төзү турында

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы 3 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2022 елның 1 сентябреннән «Татарстан Республикасы Дәүләт юридик бюросы» дәүләт казна учреждениесен (алга таба - казна учреждениесе) төзү турындагы тәкъдимен Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү, Татарстан Республикасында халыкка хокукый мәгълүмат бирү һәм хокукый белем бирү эшчәнлеген аның максатлары итеп билгеләп кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

казна учреждениесе үз эшчәнлеген гамәлгә ашыруга 2022 елның 1 октябреннән дә соңга калмыйча керешә;

казна учреждениесен гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы башкара;

казна учреждениесе хезмәткәрләренең иң чик штат саны 10 берәмлек тәшкил итә.

3. «Татарстан Республикасы дәүләт юридик бюросы» дәүләт казна учреждениесенең кушымтада бирелгән структурасын расларга.

4. Татарстан Республикасы Ююстиция министрлыгы буенча:

30 көн эчендә казна учреждениесе уставын расларга һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган кирәкле оештыру чараларын гамәлгә ашырырга;

казна учреждениесе уставын раслаганнан соң 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына казна учреждениесен

оператив идарә хокукында беркетү өчен Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте исемлеген җибәрергә;

30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасының тиешле норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр кертергә.

5. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына, казна учреждениесе уставын раслаган көннән алып 30 көн эчендә Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтенең оператив идарәсе хокукында казна учреждениесен беркетергә, аның эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәк.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин